ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРБАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӨРБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
«31» январь 2020 г.

**КАРАР**
№ 3

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегендә, хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган, җирләү буенча хезмәтләрнең бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 маендагы карары, «Татарстан Республикасында Күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» Россия Федерациясе хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бербаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 февраленнән Балтач муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 26 нчы мартындагы 10 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә. baltasi.tatarstan.ru к

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Бөрбаш авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Галимуллин

Бөрбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 31 январь аенда кабул ителгән 3 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегендә хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең 2020 елның 1 февраленнән бәясе

| Хезмәт исеме | Бәясе, сумнарда |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү ечен кирәк булган табут һәм башка әйберләрне бирү, китерү | 2695,27 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 760,19 |
| 4. Мәетне күмү (каберне казу һәм күмү) | 2669,4 |
| **Барлыгы** | 6124,86 |

Бөрбаш авыл җирлеге башкарма
комитетының 2020 елның 31 январь
аенда кабул ителгән 3 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Бөрбаш авыл җирлегендә хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең 2020 елның 1 февраленнән бәясе

| Хезмәт исеме | Бәясе, сумнарда |
|---|---|
| 1. Җирләү ечен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү, киендерү | 232,12 |
| 3. Җирләү өчен кирәк булган табут һәм башка әйберләрне бирү, китерү | 2463,15 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка илтү | 760,19 |
| 5. Мәетне күмү (каберне казу һәм күмү) | 2669,4 |
| **Барлыгы** | 6124,86 |